КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 сентябрь г.Казань № 808

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 236 статьясындагы 2 пункты һәм $236^1$ статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $93^1$ статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргa:

«Финанс оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасын банк депозитларына урнаштыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында» 2005 ел, 23 декабрь, 621 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанс оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасын банк депозитларына урнаштыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында» 2005 ел, 23 декабрь, 621 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 ел, 28 декабрь, 639 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанс оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасын банк депозитларына урнаштыру хокукына ачык конкурс үткәрү турында» 2005 ел, 23 декабрь, 621 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 11 июль, 487 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип банк депозитларына акча урнаштырыла алган кредит оешмаларының банк депозитларына Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны (алга таба – акча) урнаштыру процедурасын һәм шартларын билгели.

1.2. Банк депозитларына акча урнаштыру Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Акча бары бу Тәртиптә каралган таләпләргә туры килә торган һәм Министрлык белән бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча банк депозитларына акча урнаштыру турында генераль килешү (алга таба – Генераль килешү) төзегән кредит оешмаларында гына банк депозитларына урнаштырылырга мөмкин.

1.4. Әгәр дә 2015 елның 1 гыйнварына кредит оешмаларына карата яки кредит оешмаларын контрольдә тоткан йә аларга шактый йогынты ясаган затларга карата халыкара санкцияләр гамәлдә булса һәм кредит оешмалары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карары белән билгеләнсә, акча бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән (бу Тәртипнең 2.1 пунктындагы «в» пунктчасында билгеләнгән таләпләрдән тыш) таләпләргә туры килә торган кредит оешмаларындагы банк депозитларына урнаштырылырга мөмкин.

1.5. Россия Федерациясенә карата санкция йогынтысы чараларын куллануга бәйле рәвештә, кредит оешмасы тарафыннан аерым тармакларга, аерым оешмаларга карата чикләүләр кулланылган яки кредит оешмасы тарафыннан мондый чикләүләр куллану рисклары (куркынычы) булган очракта, акча бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмаларындагы банк депозитларына урнаштырыла алмый. Әлеге кредит оешмалары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карары белән билгеләнә.

1.6. Банк депозитларына акча урнаштыру максатларында үткәрелә торган процедуралар турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

## II. Банк депозитларына акча урнаштырыла алган кредит оешмаларына карата таләпләр

2.1. Акча түбәндәге таләпләргә туры килә торган кредит оешмаларындагы банк депозитларына урнаштырыла:

а) кредит оешмасы универсаль лицензияле банк булып тора;

б) кредит оешмасының бу пунктның «а», «в», «г» һәм «д» пунктчаларында каралган таләпләргә туры килүен тикшерү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкында булган хисаплылык буенча кредит оешмасының кимендә 25 млн.сум күләмендә үз акчасы (капиталы) булу;

в) түбәндәге таләпләрнең берсенә туры килү:

кредит оешмасының кимендә 100 млрд.сум күләмендә үз акчасы (капиталы) булу һәм Россия Федерациясе Үзәк банкының яки Россия Федерациясенең турыдан-туры яки турыдан-туры аңа карамаган контролендә булу (Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан кредит оешмасы «Россия Федерациясенең оборона-сәнәгать комплексы һәм иминлеге өчен стратегик әһәмияткә ия булган хуҗалык җәмгыятьләре тарафыннан банк счетлары һәм аккредитивлар ачу турында, банк кертеме шартнамәләрен, кыйммәтле кәгазьләрнең ияләре реестрын алып баруга шартнамә төзү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 21 июлендәге 213-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 3 өлеше нигезендә үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган кредит оешмалары исемлегенә кертелү);

кредит рейтингы Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгы (Акционерлык җәмгыяте) кредит рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен илкүләм рейтинг шкаласы буенча «A-(RU»)) дәрәҗәсеннән түбән булмау һәм кредит рейтингы «Эксперт РА» рейтинг агентлыгы» акционерлык җәмгыяте кредит рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен илкүләм рейтинг шкаласы буенча «ruA-» дәрәҗәсеннән түбән булмау;

г) элегрәк Министрлык урнаштырган банк депозитлары буенча кредит оешмасының үз вакытында түләнмәгән бурычы булмау;

д) кредит оешмасының «Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне мәҗбүри иминләштерү системасында катнашуы.

Банк депозитларына акча җәлеп итәргә ниятләгән кредит оешмасы әлеге оешманың бу пункттагы «б» пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерүгә кирәкле мәгълүматны Министрлыкка ачу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкына ризалык бирә.

## III. Кредит оешмасының Генераль килешү төзергә ниятләү турында мөрәҗәгатьнамәсен бирү

3.1. Банк депозитларына акча урнаштыруда катнашу өчен кредит оешмасы бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Генераль килешү төзергә ниятләү турында Министрлыкка язма мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгатьнамә) кертә.

3.2. Кредит оешмасы мөрәҗәгатьнамәгә түбәндәгеләрне терки:

а) банк операцияләрен гамәлгә ашыруга лицензиянең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган яки нотариуста расланган күчермәсен;

б) кредит оешмасының нотариуста расланган гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

в) җитәкче һәм баш бухгалтер вәкаләтләрен раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган яки нотариуста расланган күчермәләрен;

г) мөрәҗәгатьнамәгә, Генераль килешүгә һәм банк депозиты шартнамәсенә имза кую өчен әлеге документларны имзаларга вәкаләтле затлар имзасы үрнәкләре булган ышанычнамәләрне (аларга кредит оешмасының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имза куйганда таләп ителми);

д) кредит оешмасының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы үрнәкләре һәм мөһер оттискы (булганда) бирелгән, нотариуста расланган имзалар үрнәкләре һәм мөһер оттискы белән карточка;

е) «Кертемнәрне иминләштерү агентлыгы» дәүләт корпорациясенең кредит оешмасын кертемнәрне мәҗбүри иминләштерү системасында катнашучы банклар реестрына кертү турындагы таныклыгының нотариуста расланган күчермәсен;

ж) салым органының мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата кредит оешмасы тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәсе үтәлү турында белешмә кәгазен; ә кредит оешмасының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булган очракта, шулай ук салым органының мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплар торышы турында белешмә кәгазе теркәлә;

з) кредит оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының мәҗбүри резерв таләпләре үтәлү турында һәм мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкы алдында үз вакытында түләнмәгән бурычы булмау хакында кредит оешмасының аның җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган хатын;

и) кредит оешмасының мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата Россия Банкының «Кредит оешмаларының хисаплылык исемлеге, формалары һәм формаларны тутыру һәм Россия Федерациясе Үзәк банкына кертү тәртибе турында» 2018 елның 8 октябрендәге 4927-У номерлы күрсәтмәсендә (алга таба – Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсе) билгеләнгән 0409102 нче форма буенча төзелгән һәм кредит оешмасы җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган финанс нәтиҗәләре турындагы хисапны яки мондый хисапның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәсен;

к) кредит оешмасының мәҗбүри нормативлары һәм башка эшчәнлек күрсәткечләре турындагы мәгълүматны һәм мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсендә билгеләнгән 0409135 һәм 0409118 нче формалары буенча төзелгән һәм кредит оешмасы җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган кредит рискы

концентрациясе турындагы мәгълүматларны яки мондый хисапларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

л) мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсендә билгеләнгән 0409123 нче форма буенча төзелгән һәм кредит оешмасы җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган үз акчасы (капиталы) буенча исәп-хисапны («Базель III») яки мондый исәп-хисапның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәсен;

м) мөрәҗәгатьнамә кергән датага кадәр килгән соңгы хисап датасы хәленә карата Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсендә билгеләнгән 0409101 нче форма буенча төзелгән һәм кредит оешмасы җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган кредит оешмасының бухгалтерлык исәбе счетлары буенча әйләнештәге исемлекне яки мондый әйләнештәге исемлекнең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәсен;

н) мөрәҗәгатьнамә кергән датага «Россия Федерациясе Үзәк банкы (Россия Банкы) турында» 2002 елның 10 июлендәге 86-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри нормативларны бозган өчен кредит оешмасына карата Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан кулланылган һәм гамәлдә булган йогынты ясау чаралары булмау турында кредит оешмасының аның җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган хатын;

о) документларның кредит оешмасы җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән (булганда) расланган исемлеген.

3.3. Кредит оешмасы Генераль килешү шартларына кертү өчен мөрәҗәгатьнамәдә Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсендә ачылган корреспондентлык счеты (субсчеты) реквизитларын күрсәтә.

3.4. Бу Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге өчен кредит оешмасы җавап бирә.

## IV. Мөрәҗәгатьнамәне карап тикшерү, Генераль килешүне төзү һәм өзү

4.1. Министрлык, кредит оешмасыннан мөрәҗәгатьнамә һәм документлар алынган көннән 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны карап тикшерә һәм Генераль килешүне төзү яки төзүдән баш тарту турында боерык рәвешендә карар кабул итә.

4.2. Генераль килешүне төзүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

кредит оешмасының бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

мөрәҗәгатьнамәнең билгеләнгән формага туры килмәве;

бу Тәртипнең 3.2 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бу Тәртипнең 3.2 пунктында каралган документларның тулы күләмдә тапшырылмавы.

4.3. Министрлык тарафыннан Генераль килешү төзү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык мондый карар кабул ителгән көннән биш эш көне

эчендә Генераль килешүгә имза куя һәм аны кредит оешмасына ике нөсхәдә кредит оешмасының алу фактын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән җибәрә.

Министрлык тарафыннан Генераль килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык, мондый карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, кредит оешмасына, мондый карарны кабул итү өчен нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, җибәрү фактын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә.

4.4. Кредит оешмасы, Министрлыктан Генераль килешү алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, аңа кул куя һәм Генераль килешүнең имзаланган бер нөсхәсен Министрлыкка аның алу фактын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән тапшыра.

4.5. Кредит оешмасы тарафыннан бу Тәртипнең 4.4 пунктында күрсәтелгән срокта имзаланган Генераль килешү тапшырылмаган очракта, Генераль килешү төзелмәгән дип санала. Бу очракта кредит оешмасының яңадан бирелгән мөрәҗәгатьнамәсе Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 4.4 пунктында күрсәтелгән, имзаланган Генераль килешүне тапшыру срогы чыккан көннән ике айдан да иртәрәк булмаган вакытта карап тикшерелергә мөмкин.

4.6. Бу Тәртипнең 4.2 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан Генераль килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, кредит оешмасының яңа мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан әлеге карар кабул ителгән көннән ике айдан да иртәрәк булмаган вакытта һәм кредит оешмасы тарафыннан Генераль килешү төзүдән баш тартуга сәбәп булган кимчелекләр бетерелгәннән соң гына карап тикшерелергә мөмкин.

4.7. Министрлык белән Генераль килешү төзегән кредит оешмасы, кредит оешмасы тарафыннан депозит суммасын кире кайтару, депозит суммасына процентлар һәм штраф процентлары (пенялар) түләү буенча йөкләмәләр бозылган очракта, счет иясеннән башка, Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан акчаны Министрлыкның кушуы буенча кредит оешмасының Россия Федерациясе Үзәк банкындагы корреспондентлык счетыннан (субсчетыннан) Министрлык файдасына күчерү өчен Министрлыкка хокук бирә.

Кредит оешмасы әлеге хокукны бирүне раслый торган документларның күчермәләрен Министрлыкка кертә.

4.8. Министрлык, кредит оешмасы тарафыннан бу Тәртипнең 4.7 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәсе (күчермәләре) Министрлыкка тапшырылмаган очракта, кредит оешмасына банк депозиты шартнамәләрен төзүгә заявкалар сайлап алуда катнашырга рөхсәт итми.

4.9. Генераль килешүнең гамәлдә булу срогы бер ел тәшкил итә.

Гамәлдә булу срогы чыкканнан соң, Генераль килешү кредит оешмасы тарафыннан барлык шартлар намус белән үтәлгәндә шул ук шартларда шул ук срокка озайтыла.

Кредит оешмасы Генераль килешү үз көченә кергән (Генераль килешү озайтылган) көннән бер ел эчендә Министрлык белән банк депозиты турында бер шартнамә дә төземәгән очракта, Генераль килешү озайтыла алмый. Бу очракта яңа Генераль килешү төзү әлеге кредит оешмасы тарафыннан Генераль килешүнең гамәле туктатылган көннән алты айдан да иртәрәк булмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

4.10. Генераль килешүне өзгән очракта, Генераль килешүне өзүче як бу хакта икенче якка алдан язма хәбәр итә.

Министрлык тарафыннан Генераль килешүне өзү нияте турындагы язма хәбәрнамә кредит оешмасына җибәрелгән яки Министрлык тарафыннан кредит оешмасыннан алынган көннән Министрлык кредит оешмасына банк депозиты шартнамәләрен төзүгә заявкалар сайлап алуда катнашуга рөхсәт бирми.

## V. Акчаны банк депозитларына урнаштыруга әзерлек

5.1. Акчаны урнаштыруга әзерлек Министрлык тарафыннан Генераль килешү төзегән кредит оешмалары белән банк депозиты шартнамәләрен төзүгә заявкалар сайлап алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

5.2. Министрлык боерык рәвешендә банк депозиты шартнамәләре төзүгә заявкалар сайлап алуны үткәрү турында карар кабул итә, анда түбәндәгеләрне билгели:

а) заявкалар кабул итү срогы һәм аларны сайлап алуны үткәрү датасы;

б) банк депозитларына урнаштырыла торган акчаның максималь һәм минималь күләме;

в) акчаны урнаштыру срогы (акчаны кертү датасын һәм акчаны кире кайтару датасын кертеп);

г) банк депозитларына акча урнаштыруның минималь процент ставкасы;

д) бер кредит оешмасыннан заявкаларның максималь саны;

е) банк депозиты шартнамәсе төре (сроклы яки махсус).

5.3. Заявкалар сайлап алуны үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң, Министрлык, заявкаларны кабул итә башлаган көннән ике көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында, бу Тәртипнең 5.2 пунктында каралган мәгълүматларны, шулай ук заявкаларны кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, заявкаларны кабул итү турында мәгълүмат урнаштыра.

5.4. Министрлык, заявкалар сайлап алуны үткәрү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкының рәсми сайтында һәм кредит оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматлар нигезендә кредит оешмаларының бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

## VI. Банк депозиты шартнамәләрен төзүгә заявкалар сайлап алуны үткәрү

6.1. Министрлык Генераль килешү төзегән кредит оешмаларыннан заявкалар кабул итә.

6.2. Заявкалар кредит оешмасы тарафыннан бу Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча кәгазь чыганакта тапшырыла.

6.3. Заявка аерым беркетелгән конвертта кредит оешмасының рәсми тулы исемен, почта адресын һәм «Банк депозиты шартнамәсе төзүгә заявка» тамгасы белән бирелә.

Министрлык заявканы алган көнне конвертка заявканың керү датасын, вакытын һәм теркәүгә алуның керү номерын язып куя.

6.4. Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

а) заявкага имза куюга вәкаләтле затларга ышанычнамәләр (кредит оешмасының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имза куйганда таләп ителми);

б) кредит оешмасының депозит суммасын кире кайтару, депозит суммасына процентлар һәм штраф процентларын (пенялар) түләү буенча йөкләмәләре бозылган очракта, счет иясеннән башка, Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсе тарафыннан акчаны Министрлыкның кушуы буенча кредит оешмасының Россия Федерациясе Үзәк банкындагы корреспондентлык счетыннан (субсчетыннан) Министрлык файдасына бәхәссез күчерү өчен Министрлыкка хокук бирү турындагы кредит оешмасының корреспондентлык счеты (субсчеты) шартнамәсенә өстәмә килешүнең кредит оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган күчермәсе.

Заявкалар кабул итү срогы тәмамланганнан соң кредит оешмасы тарафыннан бирелгән заявкалар Министрлык тарафыннан, карап тикшерелмичә, кире кайтарыла.

6.5. Кредит оешмасы заявканы бу Тәртипнең 5.2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән акча чикләрендә бирә.

6.6. Кредит оешмасы, заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганга кадәр, заявканы кире алырга хокуклы. Заявканы кире алу турындагы хәбәрнамә кредит оешмасы тарафыннан Министрлыкка ирекле язма рәвештә бирелә.

6.7. Әгәр дә заявкаларны кабул итү срогы тәмамлану вакытына кредит оешмаларыннан бер заявка да кермәсә йә кабул ителгән заявкаларда күрсәтелгән процент ставкалары Министрлык тарафыннан билгеләнгән акча урнаштыруның минималь процент ставкасыннан түбәнрәк булса, сайлап алу уздырылмаган дип санала, бу хакта Министрлык заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән өч эш көне эчендә боерык рәвешендә карар кабул итә һәм аны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра.

6.8. Заявкалар аларны сайлап алуны үткәрү көнендә заявкага лимит чыкканга кадәр чират тәртибендә карап тикшерелә.

Министрлык заявкаларны карап тикшергән көннән бер эш көне эчендә заявкаларны кабул итү яки кабул итүдән баш тарту турында боерык рәвешендәге карар кабул итә, аңа банк депозиты шартнамәләрен төзү өчен сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителгән кредит оешмаларының заявкалары исемлеген терки.

6.9. Заявкаларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

заявканың бу Тәртипнең 6.3 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

заявканың билгеләнгән формага туры килмәве;

бу Тәртипнең 6.4 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бу Тәртипнең 6.4 пунктында каралган документларның тулы күләмдә тапшырылмавы;

заявкада акча урнаштыруга процент ставкасын акча урнаштыруның минималь процент ставкасыннан түбән итеп күрсәтү һәм (яки) Министрлык тарафыннан билгеләнгән акча урнаштыру срогына туры килмәү;

бер кредит оешмасыннан заявкаларның Министрлык тарафыннан билгеләнгән максималь санынnan артуы.

Заявка кабул ителмәгән очракта, Министрлык заявканы кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә кредит оешмасына, заявканы кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, җибәрү фактын раслау мөмкинлеге бирә торган ысул белән тиешле хәбәрнамә юллый.

6.10. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча акчаны банк депозитына урнаштыру башкарыла. Акча урнаштыру иң югары процент ставкасын тәкъдим иткән, әмма Министрлык тарафыннан билгеләнгән акча урнаштыруның минималь процент ставкасыннан түбән булмаган кредит оешмасында гамәлгә ашырыла.

Берничә кредит оешмасыннан акча урнаштыруга процент ставкалары бер күләмдә булган заявкалар кергән очракта, акча заявкаларны кабул итү көнендә заявкасы алданрак кергән кредит оешмасындагы банк депозитына урнаштырыла.

Акча урнаштыруга иң югары процент ставкасын тәкъдим иткән кредит оешмасы тарафыннан банк депозитына кредит оешмасы урнаштыра алган акча күләме Министрлык тарафыннан билгеләнгән акча күләменнән кимрәк белдерелгән очракта, акчаның калган өлеше өчен банк депозиты шартнамәләре акча урнаштыру өчен заявкаларында иң югары процент ставкасын күрсәткән кредит оешмалары белән Министрлык тарафыннан билгеләнгән акча күләме беткәнгә кадәр заявкаларның керү чираты тәртибендә төзелә.

6.11. Министрлык, сайлап алуны үткәрү көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында боерык рәвешендәге карар кабул итә; анда сайлап алу нәтиҗәләре буенча банк депозиты шартнамәләре төзелә торган кредит оешмалары исемлеге, һәр кредит оешмасы буенча акча урнаштыруга процент ставкалары күләме һәм банк депозитына урнаштыру суммалары күрсәтелә.

6.12. Министрлык, сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләрен Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра һәм сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны кредит оешмаларына хәбәрнамә җибәрү фактын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән язма хәбәр итә.

## VII. Банк депозиты шартнамәләрен төзү

7.1. Министрлык заявкалар буенча үткәрелгән сайлап алу нәтиҗәләре нигезендә кредит оешмалары белән банк депозиты шартнамәләрен төзи.

7.2. Банк депозиты шартнамәләрен төзү Генераль килешүләр шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

7.3. Банк депозиты шартнамәләре срокны яки махсус шартнамә рәвешендә төзелергә мөмкин. Банк депозиты шартнамәсенең төрен үзгәртү ул гамәлдә булган вакытта рөхсәт ителми.

7.4. Банк депозиты шартнамәләре Министрлыкның бу Тәртипнең 5.2 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрү турындагы боерыгында күрсәтелгән кредит оешмаларында акча урнаштыру срогына һәм Министрлыкның бу Тәртипнең 6.11 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турындагы боерыгында күрсәтелгән акча урнаштыруга процент ставкалары һәм банк депозитына акча урнаштыру суммалары күләмендә төзелә.

7.5. Акча урнаштыру һәм аларны кире кайтару буенча операцияләр кредит оешмалары тарафыннан комиссия акчасын алмыйча гамәлгә ашырыла.

7.6. Акча урнаштыруга иң югары процент ставкасын тәкъдим иткән кредит оешмасы банк депозиты шартнамәсен төзүдән баш тарткан очракта, Министрлык акча урнаштыру өчен заявкасында иң югары процент ставкасын күрсәткән кредит оешмасы белән заявкаларның керү чираты тәртибендә банк депозиты шартнамәсен төзи.

7.7. Министрлык һәм сайлап алу нәтиҗәләре буенча банк депозиты шартнамәсе төзелә торган кредит оешмасы тарафыннан бу Тәртипнең 6.12 нче пунктында күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында Министрлыктан хәбәрнамә алган көннән биш эш көне эчендә һәр як өчен берәр банк депозиты шартнамәсе ике нөсхәдә рәсмиләштерелә һәм имзалана.

## VIII. Банк депозиты шартнамәләре буенча исәп-хисаплар ясау

8.1. Министрлык, банк депозиты шартнамәсенә имза куелган көннән соң килә торган ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык өчен кредит оешмасында ачылган депозит счетына банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән тәртиптә акча күчерә.

8.2. Депозит суммасын кире кайтару һәм депозит суммасына процентлар түләү кредит оешмасы тарафыннан банк депозиты шартнамәсе шартлары белән билгеләнгән депозитны кире кайтару көнендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Министрлык счетына банк депозиты шартнамәсендә күрсәтелгән реквизитлар нигезендә башкарыла.

8.3. Министрлык тарафыннан кредит оешмасына банк депозиты өчен өлешчә акча күчерү, шулай ук кредит оешмасы тарафыннан Министрлыкка депозит суммасын өлешчә кире кайтару һәм депозит суммасының процентын өлешчә түләү банк депозиты шартнамәсе шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.4. Кредит оешмасы тарафыннан Генераль килешү һәм депозитны Министрлыкка кире кайтаруга һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләүгә бәйле банк депозиты шартнамәсе шартлары бозылган очракта, кредит оешмасы Министрлыкка штраф процентын (пеня) түләргә тиеш.

8.5. Штраф проценты (пеня) кредит оешмасы тарафыннан депозит суммасы үз вакытында кире кайтарылмаган һәм депозит суммасына процент үз вакытында түләнмәгән һәр көн өчен үтәлмәгән йөкләмәләрнең суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының кредит оешмасы тарафыннан Генераль килешү шартлары һәм банк депозиты шартнамәсе бозылган көнгә гамәлдә булган төп ставкасы ике тапкырга арттырылган күләмдә исәпләнә һәм түләнә.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Банк депозитларына акча урнаштыру турында
_____________ номерлы генераль килешү

Казан шәһәре 20___ ел, «____»__________

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, алга таба «Министрлык» дип аталган, ____________________________________________________________________
нигезендә эш итүче ______________________________________________ йөзендә,
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
бер яктан, һәм ______________________________________________________________
(кредит оешмасының рәсми тулы һәм кыскартылган исемнәре)
____________________________________________________________________________,
алга таба «Кредит оешмасы» дип аталган, ____________________________________
_____________________________________________________________нигезендә эш итүче
______________________________________________________________________йөзендә,
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталган, түбәндәгеләр турында бу генераль килешүне (алга таба – Килешү) төзеделәр.

1. Килешүдә кулланыла торган төп төшенчәләр

Килешүдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

таләпләр – банк депозитларында акча урнаштырыла алган Кредит оешмаларына карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибендә (алга таба – Акча урнаштыру тәртибе) билгеләнгән таләпләр;

заявкалар сайлап алу – Министрлык белән банк депозиты шартнамәләрен төзү өчен Кредит оешмаларының заявкаларын сайлап алу;

депозит счеты – банк депозиты шартнамәсе нигезендә Кредит оешмасына күчерелгән акчаны исәпкә алу өчен Кредит оешмасы тарафыннан Министрлыкка ачылган банк кертеме (депозит) счеты;

депозит суммасы – Министрлык тарафыннан депозит счетына күчерелгән акча.

## 2. Килешү предметы

Килешү предметы – заявкалар сайлап алуны үткәргәндә, банк депозиты шартнамәләрен төзегәндә, депозит счетына урнаштыру өчен банк депозиты шартнамәләре нигезендә акча күчергәндә һәм банк депозиты шартнамәләрен үтәгәндә Якларның үзара мөнәсәбәтләре.

## 3. Гомуми шартлар

3.1. Килешү Министрлык тарафыннан тиешле таләпләргә туры килә торган Кредит оешмасы белән төзелә.

3.2. Кредит оешмасында банк депозитларына акча урнаштыру Министрлык тарафыннан Акча урнаштыру тәртибе нигезендә Кредит оешмасы белән банк депозиты шартнамәләрен төзү юлы белән башкарыла.

3.3. Кредит оешмасында банк депозитларына акча урнаштыруга әзерлек Министрлык тарафыннан Акча урнаштыру тәртибе нигезендә заявкалар сайлап алуны оештыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.4. Министрлык акчаны Кредит оешмасына банк депозиты шартнамәсе нигезендә күчерә.

3.5. Күчерелгән акчаны исәпкә алу өчен Кредит оешмасы Министрлыкка депозит счетын ача.

3.6. Кредит оешмасы бу Килешүнең 5 бүлеге нигезендә депозит суммасына процентлар күчерә.

3.7. Кредит оешмасы Министрлыкка бу Килешүнең шартлары нигезендә депозит суммасын кире кайтара һәм исәпләнгән процентларны түли.

## 4. Депозит суммасын күчерү һәм кире кайтару тәртибе

4.1. Министрлык Кредит оешмасына акчаны депозит счетына банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда күчерә.

4.2. Министрлыкка депозит суммасын (тулысынча яки өлешчә) кире кайтару Кредит оешмасы тарафыннан банк депозиты шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Кредит оешмасы депозит суммасын банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару көненнән дә соңга калмыйча кире кайтара. Әгәр дә депозит суммасын кире кайтару көне эш көне булмаса, Кредит оешмасы депозит суммасын аннан соң килә торган беренче эш көнендә кире кайтара.

4.4. Кредит оешмасы депозит суммасын кире кайтару көнендә Министрлыкка депозит суммасын банк депозиты шартнамәсендә күрсәтелгән реквизитлар буенча күчерә.

Кредит оешмасының депозит суммасын Министрлыкка кире кайтару буенча йөкләмәләре Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Министрлык счетына депозит суммасы кергән вакыттан үтәлгән дип санала.

## 5. Депозит суммасына процентларны исәпләү һәм түләү тәртибе

5.1. Кредит оешмасы Министрлыкка депозит суммасына банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән күләмдә процент исәпли.

5.2. Кредит оешмасы депозит суммасы өчен Министрлыкка банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару көненә (әлеге көнне кертеп) яисә, бер елда календарь көн саныннан (шул ук эзлеклелектә 365 яки 366 көн) чыгып, Килешүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча депозит суммасын кире кайтару көненә депозит счетына депозит суммасы кергән көннең икенче көненнән процентлар исәпли.

Әгәр дә процентлар исәпләнә торган чорның көннәре төрле сандагы көннәр белән календарь елларга туры килсә (шул ук эзлеклелектә 365 һәм 366 көн), календарь ел 365 көннән килгән көннәр өчен процентлар бер елга 365 календарь көн исәбеннән, ә календарь ел 366 көннән килгән көннәр өчен – бер елга 366 календарь көн исәбеннән чыгып исәпләнә.

5.3. Кредит оешмасы, банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару көненнән яисә башка нигезләр буенча депозит суммасын кире кайтару көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка депозит суммасына исәпләнгән процентларны түли. Әгәр дә депозит суммасын кире кайтару көне эш көне булмаса, депозит суммасына процентлар Кредит оешмасы тарафыннан аннан соң килә торган беренче эш көнендә түләнә.

5.4. Кредит оешмасы Министрлыкка депозит суммасына исәпләнгән процентларны банк депозиты шартнамәсендә күрсәтелгән реквизитлар буенча күчерә.

Кредит оешмасының депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләү буенча йөкләмәләре Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Министрлык счетына процентлар суммасы кергән вакыттан үтәлгән дип санала.

## 6. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

6.1. Министрлыкның хокуклары:

6.1.1. Заявкалар сайлап алу йомгаклары буенча кабул ителгән карар нигезендә Кредит оешмасы белән банк депозиты шартнамәсен төзергә.

6.1.2. Банк депозиты шартнамәсе нигезендә акчаны депозит счетына күчерергә.

6.1.3. Түбәндәге очракларда Кредит оешмасыннан депозитлар суммасын үз вакытыннан алда кире кайтаруны һәм, банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән процент ставкасыннан чыгып, депозитлар суммасына исәпләнгән процентларны түләүне таләп итәргә:

Кредит оешмасы таләпләргә туры килүдән туктаганда;

Кредит оешмасының Министрлык белән төзелгән банк депозиты турындагы башка шартнамәләр буенча депозит суммасына исәпләнгән процентларны һәм депозит суммасын кире кайтару буенча йөкләмәләре үз вакытында үтәмәве банк депозиты турындагы тиешле шартнамәдә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару көненнән алып ике эш көненнән артыграк тәшкил иткәндә.

6.1.4. Килешү шартларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматларны Кредит оешмасыннан соратып алырга.

6.1.5. Банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләү яисә, бер елда календарь көн саныннан (шул ук эзлеклелектә 365 яки 366 көн) чыгып, Килешүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча депозит суммасын кире кайтару срогы чykканнан соң, Кредит оешмасыннан депозит суммасын һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны алырга.

6.1.6. Кредит оешмасы тарафыннан Килешү шартлары бозылган очракта, Килешү шартларында каралган чараларны күрергә, шулай ук депозит суммасын кире кайтару һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны һәм штраф процентларын (пеняларны) түләү буенча Кредит оешмасының үз вакытында түләнмәгән бурычлар суммасын Кредит оешмасының Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсендә ачылган корреспондентлык счетыннан (субсчетыннан) Министрлык файдасына Министрлыкның инкассо йөкләмәсе нигезендә, счет иясеннән башка, бәхәссез тәртиптә күчерү турындагы таләп белән Килешүнең 7.2 пунктындагы 7.2.6 пунктчасында күрсәтелгән корреспондентлык счеты (субсчеты) шартнамәсенә өстәмә килешү төзегән Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсенә мөрәҗәгать итәргә.

6.2. Министрлыкның бурычлары:

6.2.1. Кредит оешмасына бу Килешүнең шартларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматларны бирергә.

## 7. Кредит оешмасының хокуклары һәм бурычлары

7.1. Кредит оешмасының хокуклары:

7.1.1. Заявкалар сайлап алуда катнашырга.

7.1.2. Килешү шартларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматларны Министрлыктан соратып алырга.

7.2. Кредит оешмасының бурычлары:

7.2.1. Заявкаларны сайлап алу йомгаклары буенча Министрлык белән банк депозиты шартнамәсе төзергә.

7.2.2. Банк депозиты шартнамәсе нигезендә Министрлыктан акча алырга һәм күчерелгән сумманы исәпкә алу өчен Министрлыкка аерым депозит счетын ачарга.

7.2.3. Банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасын кире кайтару көнендә яисә Килешүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча депозит суммасын кире кайтару көнендә Министрлыкка депозит суммасын кире кайтарырга һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләргә.

7.2.4. Килешүнең 6.1 пунктындагы 6.1.3 пунктчасында күрсәтелгән очракларда, Министрлыкка депозит суммасын кире кайтарырга һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләргә.

Әлеге очракларда процентлар, депозит счетына күчерелгән депозит суммасыннан Кредит оешмасы файдаланган көннәр саныннан чыгып, Кредит оешмасы тарафыннан исәпләнә.

7.2.5. Министрлык белән килештереп, Килешүне үтәүгә бәйле мәгълүматны ачарга.

7.2.6. Кредит оешмасы тарафыннан депозит суммасын кире кайтару, депозит суммасына исәпләнгән процентларны һәм штраф процентларын (пенялар) түләү йөкләмәләре бозылган очракта, счет иясеннән башка, Министрлыкның инкассо йөкләмәсе нигезендә акчаны Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсе Кредит оешмасының корреспондентлык счетыннан (субсчетыннан) Министрлык файдасына бәхәссез күчерү өчен Министрлыкка хокук бирү турында Кредит оешмасына хезмәт күрсәтүче Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсе белән Кредит оешмасының корреспондентлык счеты (субсчеты) шартнамәсенә өстәмә шартнамә төзергә.

## 8. Йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Якларның җаваплылыгы

8.1. Килешү буенча йөкләмәләр үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары һәм Килешү нигезендә җаваплы бирә.

8.2. Яклар, Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләнүче җиңеп булмый торган көч вакыйгаларына бәйле рәвештә, Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җавап бирмиләр.

8.3. Кредит оешмасы тарафыннан Килешүнең депозит суммасын Министрлыкка кире кайтаруга һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны түләүгә бәйле шартлары бозылган очракта, Кредит оешмасы Министрлыкка штраф процентларын (пеня) исәпләргә һәм түләргә тиеш.

8.4. Штраф процентлары (пеня) Кредит оешмасы тарафыннан депозит суммасын Министрлыкка үз вакытында кире кайтармаган һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны үз вакытында түләмәгән һәр көн өчен депозит суммасын кире кайтару һәм банк депозиты шартнамәсендә билгеләнгән депозит суммасына процентлар түләү көненнән соң килә торган көннән йә Килешүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча депозит суммасын кире кайтару көненнән башлап банк депозиты шартнамәсе буенча йөкләмәләрне фактта үтәгән көнгә (әлеге көнне кертеп) кадәр түләнә.

Штраф проценты (пеня) Кредит оешмасы тарафыннан, депозит суммасын Министрлыкка кире кайтару һәм депозит суммасына процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең суммасыннан чыгып, Кредит оешмасы тарафыннан Килешү шартлары бозылган көнгә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган төп ставкасы ике тапкырга арттырылган күләмдә түләнә.

Штраф процентларын (пенялар) түләү Кредит оешмасын Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүдән азат итми.

Штраф процентлары (пеня) Кредит оешмасы тарафыннан, банк депозиты шартнамәсе буенча йөкләмәләрне фактта үтәгән көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Министрлык счетына банк депозиты шартнамәсендә күрсәтелгән реквизитлар буенча түләнә.

Кредит оешмасының исәпләнгән штраф процентларын Министрлыкка түләү буенча йөкләмәләре Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Министрлык счетына штраф процентлары (пенялар) суммасы кергән вакыттан үтәлгән дип санала.

## 9. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Килешү яки аңа бәйле рәвештә барлыкка килә торган барлык бәхәсләр яки каршылыклар Яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә. Бәхәсләрне һәм каршылыкларны сөйләшүләр юлы белән җайга салу мөмкин булмаган очракта, алар Татарстан Республикасы Арбитраж судында хәл ителергә тиеш.

## 10. Килешүгә үзгәреш кертү һәм аны өзү тәртибе Килешүнең гамәлдә булу срогы

10.1. Килешүгә кертелгән теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр дә алар язма рәвештә башкарылган һәм Якларның имзалары куелган булса, үз көченә ия.

10.2. Бу Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүдән берьяклы баш тарту һәм Килешү шартларына берьяклы үзгәреш кертү (Россия Федерациясе законнарында, шулай ук Килешүнең 10.4 һәм 10.6 пунктларында каралган очраклардан тыш) рөхсәт ителми.

10.3. Бу Килешү Яклар имзаларын куйган көннән үз көченә керә. Бу Килешүнең гамәлдә булу срогы бер ел тәшкил итә. Килешүнең гамәлдә булу срогы чыкканда, Яклар аның барлык шартларын намус белән үтәгәндә Яклар Килешүнең гамәлдә булу срогын шул ук шартларда һәм шул ук срокка озайтырга хокуклы.

Әгәр дә Якларның берсе дә, Килешүнең гамәлдә булу срогы чыкканга кадәр 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, аның гамәлен туктату турында белдермәсә, Килешүнең гамәлдә булу срогы бер елга озайтылган дип санала.

10.4. Якларның һәркайсы Килешүне берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы.

Гамәлдәге банк депозиты шартнамәләре булганда, Килешүне өзү көне булып Кредит оешмасы тарафыннан депозитларның барлык суммаларын кире кайтару, депозитлар суммасына исәпләнгән процентларны һәм штраф процентларын (пенялар) түләү көне тора.

10.5. Килешүне өзгән очракта, Килешүне өзүче Як, өзү датасына кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу турыда башка Якка язмача хәбәр итә.

10.6. Килешү түбәндәге очракларда Министрлык тарафыннан берьяклы тәртиптә өзелергә тиеш:

Кредит оешмасы тарафыннан депозит суммасын кире кайтару һәм депозит суммасына исәпләнгән процентларны һәм штраф процентларын (пенялар) түләү буенча йөкләмәләр үтәлмәгәндә яки үз вакытында үтәлмәгәндә;

Килешү төзелгәннән соң, Кредит оешмасының таләпләргә туры килмәү факты билгеләнгәндә;

Кредит оешмасы тарафыннан банк депозиты шартнамәсен төзүдән баш тартканда.

## 11. Башка шартлар

11.1. Кредит оешмасы Министрлык тарафыннан Кредит оешмасына карата таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерү үткәрү белән ризалаша.

11.2. Кредит оешмасы Килешү буенча үз хокукларын һәм йөкләмәләрен өченче якка бирергә хокуксыз.

11.3. Яклар заявкаларны сайлап алу Министрлык тарафыннан Акчаны урнаштыру тәртибе нигезендә үткәрелүен таныйлар.

11.4. Кредит оешмасы Килешүгә имза куелган көндә Министрлыкка түбәндәгеләрне җибәрә:

Килешү нигезендә банк депозиты шартнамәләренә имза куярга вәкаләтле затлар исемлеген;

Министрлык белән заявкаларны сайлап алу йомгаклары буенча банк депозиты шартнамәсен төзү өчен Кредит оешмалары заявкаларын әзерләүгә вәкаләтле затларның элемтәгә керү өчен телефоннарын.

11.5. Банк депозиты шартнамәсен төзү өчен үткәрелгән заявкаларны сайлап алу йомгаклары буенча бәяләмә банк депозиты шартнамәсен төзү өчен банк тарафыннан тәкъдим ителгән форманы исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

11.6. Яклар үз реквизитларының, бу Килешүнең 11.4 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле затлар исемлегенең, счетлар реквизитларының үзгәрүе, шулай ук Килешүне үтәүгә бәйле башка үзгәрешләр кертелүе турында бер-берсенә үз вакытында хәбәр итәргә бурычлы.

11.7. Килешүдә билгеләнгән таләпләр нигезендә бирелә торган мәгълүмат белән алмашу кәгазь чыганакларда гамәлгә ашырыла.

11.8. Килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, һәр Як өчен берәр нөсхәдә _____ биттә төзелде.

12. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Финанс министрлыгы | ____________________________________<br>(Кредит оешмасының рәсми тулы исеме) |
| Урнашу урыны, адресы __________<br>__________________________________ | Урнашу урыны, адресы ________________<br>_____________________________________ |
| Счет реквизитлары _________________ | Счет реквизитлары ____________________ |
| ИНН ____________________________ | ИНН ________________________________ |
| КПП ____________________________ | КПП ________________________________ |
| ОГРН ___________________________ | ОГРН ______________________________ |
| Телефоны _________________________ | БИК ________________________________ |
| Факсы ___________________________ | Телефоны ___________________________ |
| | Факсы<br>_________________________________ |

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

20__ ел, «__» _________
№ ___________________

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы

Банк депозитларына акча урнаштыру турында
генераль килешү төзү нияте турында
мөрәҗәгатьнамә*

Моның белән ______________________________________________________
(кредит оешмасының рәсми тулы һәм кыскартылган исемнәре)
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән банк депозитларына акча урнаштыру турында генераль килешү төзергә ниятен белдерә.

______________________________________________________________________
(кредит оешмасының рәсми тулы һәм кыскартылган исемнәре)
банк депозитларында акча урнаштырыла алган кредит оешмаларына карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибендә (алга таба – Акча урнаштыру тәртибе) билгеләнгән таләпләргә түбәндәге өлештә туры килүен хәбәр итә;

универсаль лицензиясе булу;

үз акчасы (капиталы) _______________сум күләмендә булу;

Россия Федерациясе Үзәк банкының яки Россия Федерациясе Үзәк банкының турыдан-туры яки турыдан-туры аңа карамаган контролендә булу _______________;
(әйе/юк)

кредит рейтингы Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгы (Акционерлык җәмгыяте) кредит рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен илкүләм рейтинг шкаласы буенча һәм кредит рейтингы «Эксперт РА» рейтинг агентлыгы»

---

*Мөрәҗәгатьнамә кредит оешмасының фирма бланкында (булганда) рәсмиләштерелә.

акционерлык җәмгыяте кредит рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен илкүләм рейтинг шкаласы буенча булу _________________________________________;

(кредит рейтингы дәрәҗәсе һәм кредит агентлыгы исеме)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан элек урнаштырылган банк депозитлары буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы булмау;

«Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне мәҗбүри иминләштерү системасында катнашу.

Урнашу урыны, адресы: _______________________________________________.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан корреспонденция алу өчен почта адресы: ______________________________________________________.

Кредит оешмасының корреспондентлык счеты (субсчеты) реквизитлары һәм Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсенең исеме:

№_____________________________________________________________________

(номеры)

______________________________________________________________________

(бүлекчәнең исеме)

БИК:________________ ИНН:________________ КПП: ______________________

Акча урнаштыру тәртибенең 3.2 пунктында каралган документлар исемлеге теркәлә.

Бу мөрәҗәгатьтә һәм аңа теркәлә торган документларда күрсәтелгән мәгълүматның тулылыгына һәм дөреслегенә гарантия бирәбез.

Кушымта: ___________ б.

Кредит оешмасының
Җитәкчесе
(вәкаләтле заты) ____________________/_________/_______________________

(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

М.У. (булганда)

Башкаручы ___________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Телефоны ____________________________

(номеры)

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

20__ ел, «__» __________
№______________________

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы

_______________________________________________
(кредит оешмасының рәсми тулы исеме)

банк депозиты шартнамәсен төзүгә
заявка*

Банк депозиты шартнамәләрен төзү өчен кредит оешмаларының заявкаларын сайлап алуны үткәрү датасы 20___ елның «____»___________.

Кредит оешмасы заявка җибәрә торган Генераль килешүне төзү датасы, номеры 20___ ел, «____»___________, № ______________.

Моның белән _______________________________________________________,
(кредит оешмасының рәсми тулы исеме)

урнашкан урыны, адресы: _______________________________________________,

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан корреспонденция алу өчен почта адресы: _______________________________________________________________,

кредит оешмасының корреспондентлык счеты (субсчеты) реквизитлары һәм Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсенең исеме:

№_______________________________________________________________
(номеры)

_________________________________________________________________
(бүлекчәнең исеме)

БИК:________________ ИНН:________________ КПП:__________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм

*Заявка кредит оешмасының фирма бланкында (булганда) рәсмиләштерелә.

счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе (алга таба – Акча урнаштыру тәртибе) нигезендә исәпләнгән

______________________________________________________________
(суммасы саннар белән)

(_______________________________________________________________)
(суммасы сүзләр белән)

күләмендә акча урнаштырырга тәкъдим итә.

Депозит төре ______________________________________________.

Банк депозитларына акча урнаштыруга процент ставкасы бер елга ______ %.

Банк депозитларына акча урнаштыру срогы (акча урнаштыру датасын һәм аны кире кайтару датасын кертеп) ______________________________________.

______________________________________________________________,
(кредит оешмасының рәсми тулы исеме)

заявка бирү датасына банк депозитларына акча урнаштырыла алган кредит оешмаларына карата Акча урнаштыру тәртибендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен хәбәр итә.

Бу заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

заявкага имза куярга вәкаләтле затларга ышанычнамә (кредит оешмасының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имза куйганда таләп ителми);

кредит оешмасының депозит суммасын кире кайтару, депозит суммасына процентлар һәм штраф процентларын (пенялар) түләү буенча йөкләмәләре бозылган очракта, счет иясеннән башка, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы кушуы буенча акчаны Россия Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсе кредит оешмасының Россия Федерациясе Үзәк банкындагы корреспондентлык счетыннан (субсчетыннан) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы файдасына бәхәссез күчерү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хокук бирү турындагы кредит оешмасының корреспондентлык счеты (субсчеты) шартнамәсенә өстәмә килешүнең кредит оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган күчермәсе.

Кредит оешмасының
Җитәкчесе
(вәкаләтле заты) ____________________/________/__________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

М.У. (булганда)

Башкаручы ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Телефоны _____________________________
(номеры)

_________________________________